# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**12 нче ноябрь, 2025 нче ел** **№3**

Гамәлдәге законнар нигезендә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«2026 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарларын һәм урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар).

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, тракторчыга хезмәт шартнамәсе буенча түләү, трактор өчен өстәмә Асма җайланмалар сатып алу, МТЗ-82, ЮМЗ тракторларына запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, үлән чабу өчен БЕНЗОКОСЛАР сатып алу һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 128 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 75 кеше, бу 68 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“РИЗА” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 72 кеше тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 3 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2026 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын)  түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә .

3. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә җибәрергә:
1. Уразай торак пункты территориясен төзекләндерү:
- *юлларны кардан чистарту;*
-*дизель ягулыгы, МТЗ-82 тракторы өчен май сатып алу;*
- *тракторчы эшенә килешү буенча түләү;*
- *авария хәлендәге һәм коры утыртмаларны сүтү һәм кисү;*
-*МТЗ-82 тракторы өчен өстәмә асылмалы җайланмалар сатып алу( бульдозер, чапкыч);*
-*МТЗ-82, ЮМЗ тракторлары өчен запас частьләр сатып алу;*
- *торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар.*

2.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- *Ленин, Совет урамнары буенча юллар сатып алу һәм аларга вак таш җәю һәм автомобиль юлларын карап тотуның башка чыгымнары.*

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы                                        И.М.Фардутдинова